Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы “Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы мәктәпкәчә муниципаль бюджет учреждениесе

**“Без – бергә!”**

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы һәм мәктәп дәвамчанлыгы

проекты

Проект авторы:

“Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы” мөдире

Гыймадиева Ләйлә Мансур кызы

Ямаширмә , 2022

Кереш ……………………………………………………………............… 3

Проектның актуальлеге.......................................................................... 3

Проектның максаты һәм бурычлары.......................................................... 3 - 4

Проектның яңалыгы.................................................................................. 5

Проектны тормышка ашыру планы ............................................................ 6 – 7

Проектының тормышка ашыру этаплары ..................................................... 7

Көтелгән нәтиҗәләр.........................................................................................8

Проектны тормышка ашыуны тәэмин итү өчен кирәкле шартлар................ 8

## Кереш

Мәктәп белән балалар бакчасы белем бирүнең бер үк юнәлештә эшләүче ике чиктәш буыны ул. Әгәр бала мәктәпкә әзерлексез килсә, класста ул үзен уңайсыз хис итә, чөнки балага бөтенләй яңа булган мохиткә күнегергә туры килә. Балалар мәктәпкә ныклы әзерлек белән килсен өчен балалар бакчасы һәм мәктәп арасында дәвамчанлык булуы мөһим.

Мәктәп ягыннан караганда дәвамчанлык - балаларның балалар бакчасында алган беренчел белем һәм күнекмәләргә нигезләнеп һәм шул белемнәрне исәпкә алып барыла. Ә балалар бакчасы ягыннан караганда дәвамчанлык ул - мәктәп таләпләренә ориентлашу, мәктәптә белем алуны дәвам итү өчен кирәк булган белем һәм күнекмәләр формалаштыру.

Башлангыч мәктәп һәм балалар бакчасы арасындагы дәвамчанлык балаларны укырга әзерләү дип кенә кабул ителергә тиеш түгел. Мәктәпкәчә яшьтә бала шәхесенә иң мөһим билгеләр салына. Моның өчен мәктәп һәм бакча арасында бердәм үсеш дөньясы булдыру мөһим.

2014 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кергән мәктәпкәчә белем бирүдә федераль дәүләт белем бирү таләпләре башлангыч белем бирүдәге таләпләр арасындагы дәвамчанлыкның үзенчәлекләрен өйрәнүгә этәрә. Бала иң беренче белем бирү баскычына - балалар бакчасына килә, ә аннан соң икенче баскычка күтәрелә – мәктәпкә укырга керә. Нәкъ шушы күчү мизгелендә мәктәп һәм балалар бакчасы арасындагы дәвамчанлык “куркынычсызлык мендәре” булып торырга тиеш. Шулай итеп балалар бакчасы ул фундамент, ә мәктәп - белем бирү потенциалын үстерүче бина булып тора.

**Проектның актуальлеге**

Бүгенге көндә мәгариф системасындагы эшчәнлек көн саен үзгәреп тора. Шуны исәпкә алып, без, тәрбиячеләр, укытучылар, балаларны шул үзгәрешләрне җиңеп чыгарлык итеп тәрбияләргә тиешбез. Бүгенге көндә мәктәпләр, балалар бакчалары федераль дәүләт белем бирү стандартын гамәлгә ашыру буенча эш алып баралар, икетелле белем бирүдә тәҗрибә уртаклашалар.

Икетелле белем бирү һәм тәрбияләүдә Федераль дәүләт белем бирү стандартын гамәлгә ашыруның төп принциплары булып дәвамчанлык һәм үсеш тора. Дәвамчанлык үзе ике яклы: балаларның балалар бакчасында үз-үзләрен тотышлары, үз-үзләренә бәя бирүләре формалаша, ә бу мәктәптә ныклы белем алу өчен төп юнәлеш булып тора. Алар мәктәпкә барганда ныклы ышаныч белән баралар. Бу төр эшчәнлек белән алар мәктәп системасына бик тиз һәм җиңел ияләшәләр. Балаларның мәктәптәге өлгерешләре аларның балалар бакчасында алган белем-тәрбияләренә нигезләнә.

**Проектның максаты һәм бурычлары**

**Максат :** милли ресурс үзәк эшчәнлеге кысаларында мәктәпкәчә яшьтәге балаларга икетелле белем бирү һәм аларны тәрбияләү системасында мәктәпнең әһәмияте.

**Бурычлар:**

- икетелле белем һәм тәрбия бирүдә Федераль дәүләт белем бирү стандартын гамәлгә ашыру шартларында балалар бакчасы һәм мәктәп арасында дәвамчанлык урнаштыру;
- мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге баланың балалр бакчасы һәм мәктәп дәвамчанлыгының практик юнәлешле моделен эшләү;
- һәр балага үз мөмкинлекләрен тулаем ачарга булышу;
- балаларны мәктәп белән кызыксындыру, мәктәпкә барасы килү теләген үстерү;
- ФДББС шартларына туры китереп, балаларның мәктәпкә әзерлекләрен тәэмин итү;

- тәрбияләнүчеләрнең һәм укучыларның туган ягына, халкына, туган теленә, гореф-гадәтләренә, сәнгатенә эмоциональ кыйммәтле карашлары аша милли тәрбия бирү эшен дәвам итү.

- бергәләп эшләү формаларын һәм инновацион методларны гамәлгә кертүне дәвам итү;

- тормыш иминлеген, куркынычсызлыгын оештыруның яңа сәламәтлек саклау технологияләрен гамәлгә кертү эшен камилләштерү;

**3. Проектның яңалыгы:**

Мәктәптә укытучы, әти-әни һәм балалар белән берлектә социаль яктан файдалы проект эшчәнлеген булдыру, мәктәптә социаль яктан файдалы проект эшчәнлегенең инновацион тәҗрибәләрен булдыру.

**4. Проект эшчәнлеге түбәндәге мөмкинчелекләрне ача:**

- җәмгыять һәм халкыбыз өчен файдалы эшчәнлеккә балалар бакчасында тәрбияләнүчеләрне һәм мәктәп укучыларын җәлеп итү;

- тәрбияләнүчеләр һәм укучының шәхси тәҗрибәсе белән мәктәп тормышын уңышлы бәйләү;

- бүгенге җәмгыять шартларында шәхестә иң кирәкле булган сыйфатлар инициативалык, җаваплылык, мөстәкыйльлек кебек сыйфатлар формалаштыру;

- халыкның милли мирасын саклау, аны дәвам итүнең нигезләрен булдыру;

- тәрбияләнүчеләр һәм тәрбиячеләрнең, укучыларның һәм укытучыларның лидерлык сыйфатларын ачарга ярдәм итү.

**5. Проектны тормышка ашыру этаплары**

Проектны гамәлгә ашыру уку елы дәвамында эшләнүгә исәпләнелгән.

I этап: уку елы башы – эзләнү эше алып бару, анализ, проблемаларны ачыклау, максат кую, бурычлар, проектны тормышка ашыру планын төзү;

II этап: уку елы – практик: балалар бакчасы һәм мәктәптә проектны тормышка ашыру:

III этап:уку елы ахыры , май – анализлау. Нәтиҗәләр чыгару, конференция уздыру,

җыентык чыгару,  башлангыч сыйныф укучысының һәм мәктәпкә әзерлек төркеме тәрбияләнүчесе моделен эшләү.

**6. Көтелгән нәтиҗәләр:**

- икетелле белем һәм тәрбия бирүдә тәрбияләнүчеләр һәм укучыларның иҗади активлыкларына ирешү;
- укытучылар һәм тәрбиячеләрнең педагогик осталыкларын үстерү;
- балалар бакчасында тәрбияләнүчеләрнең һәм укучыларның социаль активлыгы арту, мәктәп белән тыгыз элемтә булдыру;
- гаиләдә, балалар бакчасында, мәктәптә милли гореф-гадәтләрне үтәү һәм башка милләтләрнең мирасына да хөрмәт белән карау;
- бала тәрбияләүдә халкыбызның гореф-гадәтләрен, йолаларын куллану;
- балаларны мәктәп, мәдәният йорты, китапханә кебек оешмаларның эшчәнлеге белән таныштыру һәм әхлаки-мәдәни чараларга җәлеп итү.

**7. Проектның тәэмин ителеше.**

- проектны тормышка ашыруда җаваплы “Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы” МББМБУ мөдире Гыймадиева Ләйлә Мансур кызы.
- проектны тормышка ашыру механизмнары “Ямаширмә “Йолдыз” балалар бакчасы” МББМБУ педагогик коллективы, Ямаширмә урта гомуми белем мәктәбе коллективы,  ата-аналар җәмәгатьчелеге, иҗтимагый партнерлык принципларына нигезләнгән.
  Иҗтимагый партнерлар : Ямаширмә гомуми урта белем мәктәбе, Ямаширмә мәдәният йорты, Биектау муниципаль районы балалар бакчалары, татар хатын – кызларының “Ак калфак” оешмасы, Ямаширмә авыл җирлеге, Ямаширмә авыл китапханәсе, Габдулла Тукай исемендәге Арча педагогоика көллияте, Мәгарифне үстерү институты.
- проектның материаль тәэмин ителеше: ноутбуклар, интерактив такта, ком такталары, күрсәтмәлелекләр;
- проектка төзәтмәләр кертү балалар бакчасының педагогик составы тарафыннан тормышка ашырыла;
- фикер алышу һәм арадаш нәтиҗәләр ясау административ һәм педагогик советта, ата-аналар җыелышларында башкарыла;

- программаны тормышка ашыруны балалар бакчасы администрациясе контрольдә тота.

## 8. “Ямаширмә гомуми урта белем мәктәбе” белән берлектә “Без бергә!” проектын тормышка ашыру планы

| № | Үткәреләчәк чаралар | Вакыты | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1. | ***Методик эш.*** | | |
| 1.1. | Эзләнү эше алып бару, анализ, проблемаларны ачыклау, максат кую, бурычлар, проектны тормышка ашыру планын төзү | Сентябрь | |
| 1.2. | Балаларны мәктәп белән таныштыру буенча перспектив планнар төзү һәм фикер алышу. | Сентябрь | Мөдир |
| 1.3. | Мәктәпкә сәяхәт. | Сентябрь | Тәрбиячеләр |
| 1.4. | Башлангыч класс укытучыларын балалар бакчасының программасы белән таныштыру. | Октябрь | Мәктәп педагоглары |
| 1.5. | Тәрбиячеләрне 1 нче класста укыту программасы белән таныштыру. | Октябрь | |
| 1.6. | Балалар бакчасында эш формалары һәм балалар белән таныштыру максатыннан укытучыларның шөгыльләргә йөреше. | Ноябрь | Мәктәп җитәкчелеге |
| 1.7. | Тәрбиячеләрнең 1 нче класс дәресләренә йөреше. | Ел дәвамында | |
| 1.8. | Балалар бакчасы чыгарылышының адаптация узу анализы, тәрбия һәм белем бирүдәге җитезсезлекләрне ачыклау максаты белән тәрбиячеләрнең 1 нче класс дәресләренә йөреше. | Ел дәвамында | |
| 1.9. | Мәктәпкә сәяхәт.<br>- Бина, класслар, спорт залы, китапханә белән таныштыру. | Ел дәвамында | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1.10. | Мәктәп музеена бару. | | |
| 1.11. | Мәктәп белән үзара эшчәнлектә театрлар, экиятләр күрсәтү. | Ел дәвамында | |
| 1.12. | Күргәзмәләр оештыру. | Ел дәвамында | |
| 1.13. | Укытучылар һәм тәрбиячеләр өчен мастер - класслар | Ел дәвамында | |
| 1.14. | Семинар – практикумнар оештыру. | | |
| 1.15 | Түгәрәк өстәләр, консультацияләр оештыру. | Ел дәвамында | |
| 1.16 | “Иң яхшы дидактик уен” бәйгесен оештыру | Апрель | |
| 1.17 | “Иң милли тәрбияче”Республика бәйгесен оештыру | Февраль | |
| 1.18 | Анализлау, җыентык чыгару , модель төзү, киләсе уку елына план төзү:<br>“Онытылып барган уеннар” җыентыгы;<br>Мәктәпкәчә яшьтәге һәм башлангыч сыйныф укучысы моделен төзү;<br>Мәктәп һәм балалар бакчасы дәвамчанлыгы моделен төзү;<br>Беренче сыйныф укучысы портфолиосы эшләү | Май – август | |
| 2. | ***Тәрбияләнүчеләр белән эш төрләре*** | | |
| 2.1 | Мәктәп турында әңгәмә | Сентябрь | |
| 2.2. | “Укытучым яши янәшә!”(Әңгәмә, кызыклы чаралар) | Октябрь | Балалар бакчасы мөдире |
| 2.3. | Мәктәп турында шигырьләр, хикәяләр уку. | Ноябрь | |
| 2.4. | “Минем киләчәк мәктәбем!” рәсемнәр бәйгесе | Декабрь | Мәктәпкә әзерлек төркеме тәрбиячеләре |
| 2.5. | “Мин – укучы” , сюжетлы – рольле уеннар | Ел дәвамында | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2.6. | Өстәл театры “ Лесная школа” | Ел дәвамында | Укытучылар |
| 2.7. | Мәктәп тормышы турында мультфильмнар карау | Ел дәвамында | |
| 2.8. | Белем бирү турында мәкальләр, әйтемнәр өйрәнү | Ел дәвамында | Мәктәп җитәкчелеге |
| 2.9. | Дидактик уен “ Собери портфель» | Гыйнвар | |
| 3. | ***Бәйрәмнәр һәм күңел ачу чаралары*** | | |
| 3.1. | 1 нче Сентябрь – Белем көне. | Сентябрь | |
| 3.2. | “Сез иң гүзәл кеше икәнсез!”, укытучылар көненә кичә. | Октябрь | Мөдир |
| 3.3. | “Сөмбеләдә кунакта”. | Октябрь | Тәрбиячеләр |
| 3.4. | “ Балкып яна Яңа ел утлары”, театральләштерелгән кичә. | Декабрь | Укытучылар |
| 3.5. | “Муса Җәлил – герой шагыйрь” әдәби кичә. | Февраль | Мәдәният йорты хезмәткәрләре |
| 3.6. | Туган тел атналыгы. | Февраль | |
| 3.7. | “Нәүрүз килә!” кичә | Апрель | Мәктәп җитәкчелеге |
| 3.8. | Җиңү бәйрәме | Май | |
| 3.9. | “Сау бул балалар бакчасы , исәнме мәктәп!” | Май | |
| 3.10. | “Балалар сабантуе | Июнь | |
| 3.11. | Хәтер һәм Кайгы көне | Июнь | |
| 4. | ***Әти-әниләр белән эш.*** | | |
| 4.1. | Әти-әниләргә мәктәп белән берлектә икетелле белем бирүнең ФДББС шартларында гамәлгә ашыру алымнарын аңлату. | сентябрь | Балалар бакчасы мөдире |
| 4.2. | Әти-әниләр белән балаларны мәктәпкә әзерләүдә ярдәм итә торган методик, педагогик, психологик | февраль | Мәктәпкә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | киңәшләрне үз эчен алган "Тиздән мәктәпкә!" күргәзмәләр оештыру. | | әзерлек төркеме тәрбиячеләре |
| 4.3 | Әти-әниләргә төрле темаларга консультацияләр, әңгәмәләр | Ел дәвамында | Укытучылар |
| 4.4 | Онытылып барган уеннарны искә төшерү, аларны уйнау, балаларга да өйрәтү. | Ел дәвамында | Мәктәп җитәкчелеге |
| 4.5 | Борынгы гореф – гадәт, йолаларны искә төшерү, аларны гамәлгә ашыру, бала күңеленә салу. | | Әти-әниләр |
| 4.6 | “Бишек җыры!” бәйгесе уздыру | Ноябрь | |
| 4.7. | “Гаиләмнең кадерле истәлекләре” , бәйге | Апрель | |
| 4.8. | Әңгәмә "Баланы мәктәпкә ничек әзерләргә" | Апрель | |
| 4.9. | Тест уздыру "Сезнең балагыз мәктәпкә әзерме?" | Апрель | |
| 4.10. | Күчмә папкалар әзерләү | Ел дәвамында | |
| 4.11. | Әти-әниләр җыелышы. (Башлангыч класс укытучыларын чакыру) | Май | |

**9. Проектның алга таба үсеше һәм тәҗрибә уртаклашу.**

- район, республика күләмендәге бәйгеләр, фестивальләрдә катнашу;
- массакүләм мәгълүмат чараларында басылу;
- милли ресурс үзәк кысаларында район һәм Республика күләмендә семинарлар уздыру;
- милли бәйрәмнәрне үткәрү.